# Рәхимов Рәфкать Вафа улы



1926 елда Зур Битаман авылында Гәбдерәхимов вафа абый гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. Алар 8 бала була. Авыр чорга туры килгән балачагы авырлыклар белән үрелеп бара аның. Туган авылында 8 еллык мәктәпне тәмамлый. Каникул вакытларында ат җигеп, колхоз эшләрендә катнаша, өорт тирәсендә ир-ат эшләрен башкара. Кечкенәдән печәнен чаба,тиресен түгә, кыскасы - бөтен авыл эшен башкарып үсә ул.

Рәфкать абыйны 17 яшьлек егет чагында, 1943 елның 5 гыйнварында , сугышка алалар. Атнадан артык арча вокзалында, аннары 4 айлап Суслонгерда була. Аларны Белоруссиянең Орша шәһәренә китерәләр. Чиратта Днепр, Неман, Березино елларын йөзеп, 40 градус салкыннарда бик нык туңа-туңа, 70 чакрым араны җәяү үтәләр.  Күзәтүче-разведчик булавыр яраланаып йөргәндә, бик каты яраланып, Вильнюс госпиталендә дәваланып чыга. 5 айдан соң, үз частенә кабат кайта. Тик бу вакытта инде элеккеге иптәшләренең берседә булмый. 1944 нче елда Кенигсберг шәһәре янында артиллериядән аткан снаряд бот сөяген каты яралый, ул кырда ятып кала. Бәхетенә,  аны шәфкать туташы күреп ала, госпитальгңңә алып кайталар. Операция ясаганнан соң, поезд белән Казанга озаталар. Анда Халтурин урамында 4 айлап дәвалана. Аннан авылга кайтаралар.

Сугыштан соң, Әминә белән гаилә корып, 5 бала үстергәннәр. Кызганычка каршы ул хатыны яшьли үлә. Бүгенге көндә Рифкать абый Маһинур апа гаиләсендә, Рим абый ,Эльмира апа тәрбиясендә, гомер кичерә.

Рәфкать абый  яшьләрнең бүгенге тормышның кадерен белүләрен, туган илне яратуларын, тырышып укуларын, олыларны, әти-әнине хөрмәт итүләрен, Бары тик яхшы гамәлләр генә кылуларын тели.

